ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

8.10.2020                    № 812

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 05.08.2019 ел, № 656 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 13.07.2020 ел, № 202-ФЗ Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 05.08.2019 ел, № 656 карары белән расланган Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең технологик схемаларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 3 пунктына "әлеге статьяның 6_2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш" сүзләрен өстәргә;

2 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 4 пунктына "әлеге статьяның 6_2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 6_2 өлеше белән тулыландырырга:

"6_2. Мондый объектның техник планында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының мәйданы турындагы мәгълүматларның проект документларында һәм (яки) төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән мәйданы турындагы мәгълүматларга карата биш проценттан да артмаган булуы, техник планда күрсәтелгән катлар, бүлмәләр (булган очракта) һәм машина урыннары саны (булган очракта) һәм проект документациясе һәм (яки) төзелешкә рөхсәтнамә булган очракта файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.".

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы                    Р.А.Газизуллин